РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 елның 22 мае** **204№**

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары турында

2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы «Татарстан Республикасы Дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары турында» карарының 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль милкендә булган күчемсез мөлкәтне (шул исәптән дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре һәм җирләрне) арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартларын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат http://pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә йөкләргә.

**Җитәкче** **И.В.Юсупов**

Расланган
Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 22 маендагы
204 номерлы Карары

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль милкендә булган күчемсез мөлкәтнеарендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору Шартлары

1. Күчемсез мөлкәттән файдаланган өчен 2020 елда каралган аренда түләвен кичектереп тору шартлары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне 2020 елда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законның 11 статьясы нигезендә кабул ителгәнчегә кадәр төзелгән һәм арендаторлар булып исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары (алга таба-аренда килешүе, кичектерү) белән расланган яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәл начарайган шартларда аеруча зыян күрүче Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләрнең арендалау шартнамәләренә карата кулланыла.

2. Кичектерү, торак биналардан тыш, күчемсез милеккә карата бирелә.

3. Кичектерү 2020 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлнең югары әзерлек режимын кертү датасыннан башлап түбәндәге шартларда бирелә:

а) аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан алып һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да артмыйча, аренда килешүе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган күләмдә түләүләр белән түләнергә тиеш;

б)Кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл югары әзерлек режимы гамәлдә булу срогына, тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл аркасында югары әзерлек режимы туктатылган көннән алып, 2020 елның 1 октябренә кадәр аренда түләвенең 50 проценты күләмендә бирелә;

в) арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яисә башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

г) кичектереп торуга бәйле рәвештә арендатор тарафыннан өстәмә түләүлә билгеләү рөхсәт ителми;

д) кичектерү торуга бирелә торган аренда түләве күләме яклар килешүе буенча киметелергә мөмкин;

е) әгәр аренда килешүендә арендатор тарафыннан коммуналь хезмәтләрдән файдаланган өчен түләүләрне һәм (яки) арендалана торган мөлкәтне карап тоту чыгымнарын аренда түләвенә кертү күздә тотылса, аренда түләвенең күрсәтелгән өлеше буенча кичектереп тору, Татарстан Республикасы территориясендә

арендага бирүче мондый хезмәтләр өчен түләүдән һәм (яки) мондый чыгымнарны түләүдән азат ителгән очраклардан тыш бирелми.

4. 3 пунктта каралган кичектереп тору шартлары мондый килешү төзү датасына карамастан, аренда шартнамәсенә карата өстәмә килешүләргә карата кулланыла.